Ләкин, мөрәҗәгать итүче фикеренчә, күрсәтелгән чорда ОДН-электр белән тәэмин ителеш өчен түләүне хисаплаганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең (алга таба — 354 номерлы Кагыйдәләр) 44 пункты кулланылырга тиеш булган, аның нигезендә ИИП булмаган фатирлар буенча фатирда һәм гомумйорт ихтыяҗлары өчен электр белән тәэмин ителеш өчен түләүләр норматив буенча башкарылырга тиеш (йорттагы урыннар милекчеләренең гомуми җыелышы карары булмаган очракта).

ОДН-электр белән тәэмин ителеш өчен хисапланган түләүләр күләме белән ризалашмыйча, гражданин Р.Х. Ибәтуллин дәгъва белән Идарәче компаниягә мөрәҗәгать иткән, аны канәгатьләндерүдән баш тартылган. Барлыкка килгән бәхәсне хәл итү өчен ул Идарәче компаниягә аның шәхси счеты буенча ОДН-электр белән тәэмин ителеш өчен хисапланган түләү күләмен яңадан исәпләү турындагы дәгъва белән судка мөрәҗәгать иткән. Казан шәһәре Авиатөзелеш район судының Татарстан Республикасы Югары судының апелляция һәм кассация инстанцияләре белән үзгәрешсез калдырылган карары белән аның таләпләрен канәгатьләндерүдән шулай ук баш тартылган.

Гражданин Р.Х. Ибәтуллин фикеренчә, Татарстан Республикасы Законының дәгъвалана торган нормалары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына коммуналь хезмәтләр күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплау тәртибен хокукый җайга салу вәкаләтен бирмиләр. Ул Күрсәтмә карала торган Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларын ялгыш аңлату нигезендә кабул ителгән дип саный, шуңа күрә аларның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек бар дип исәпли, чөнки алар күпфатирлы

йортта ОДН-электр белән тәэмин ителеш (су белән тәэмин ителеш) өчен түләүне хисаплаганда Күрсәтмәдә каралган кире пропорциональлек формуласын куллануга юл куялар. Шуның белән мөрәҗәгать итүче асылда дәгъвалана торган нормаларның аның конкрет эшендә турыдан-туры булмаса да кулланылганына күрсәтә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданин Р.Х. Ибәтуллин Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2018 елның 6 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 3 һәм 4 статьяларын Татарстан Республикасы Конституциясенең 4 (беренче өлеш), 9 (өченче өлеш), 19 (беренче өлеш), 24 (беренче һәм өченче өлешләр), 27 (беренче һәм икенче өлешләр), 51 һәм 60 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 2 өлеше буенча торак законнары әлеге Кодекстан, аның нигезендә кабул ителгән башка федераль законнардан, шулай ук алар нигезендә чыгарылган Россия Федерациясе Президенты указларыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларыннан, федераль башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларыннан, кабул ителгән Россия Федерациясе субъектлары законнарыннан һәм башка норматив хокукый актларыннан, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актларыннан тора.

Торак законнары өлкәсендә Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтләрен, шул исәптән Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 2 һәм 6 өлешләре нигезләмәләрен тормышка ашыру максатында, шулай ук дәүләт торак күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру мөнәсәбәтләрен җайга сала торган 4 статьясындагы 1 өлешенең 13 пунктын һәм 20 статьясын үтәү йөзеннән «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Законы кабул ителгән. Карала торган Татарстан Республикасы Законы гомумән күпфатирлы йортлар белән идарә итү, күпфатирлы йорттагы урыннар милекчеләренең уртак мөлкәтен тоту, коммуналь хезмәтләр күрсәтү, торак урын һәм коммуналь хезмәтләр өчен түләү кертү өлкәсендә гражданнарның торак хокукларын яклауны, шул исәптән республика дәүләт күзәтчелеген һәм муниципаль торак контролен гамәлгә ашыру юлы белән, тәэмин итүгә юнәлдерелгән.

Татарстан Республикасы Законының 3 һәм 4 статьяларындагы мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган нигезләмәләре гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү өлкәсендә хокукый җайга салу нигезләрен һәм күрсәтелгән өлкәдә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләрен җитәрлек дәрәҗәдә ачык һәм төгәл билгелиләр. Шул ук вакытта дәгъвалана торган статьяларда каралган законнар исем-

леге, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләре тулы түгел һәм әлеге Татарстан Республикасы Законнары нормалары белән чикләнмиләр һәм, димәк, шул исәптән федераль законнарда, Татарстан Республикасы Конституциясендә һәм Татарстан Республикасы законнарында, шулай ук федераль башкарма хакимият органнары белән килешүләрдә билгеләнгән башка вәкаләтләр кысаларында гамәлгә ашырыла алалар, бу Татарстан Республикасы Законының карала торган 4 статьясындагы 5 пунктында беркетелгән. Мондый җайга салу Татарстан Республикасы Конституциясе нормасына нигезләнгән, аның буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Татарстан Республикасы территориясендә Россия Федерациясе Конституциясенең, Татарстан Республикасы Конституциясенең, федераль законнарның һәм Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларының, Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үтәлешен тәэмин итә, карарлар һәм күрсәтмәләр чыгара, аларның үтәлешен тикшерә (103 статья).

Шулай итеп, гражданин Р.Х. Ибәтуллин тарафыннан дәгъва белдерелә торган закон нигезләмәләренең үзләреннән-үзе Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк һәм алар аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен ул күрсәткән аспектта боза торган буларак карала алмыйлар. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (2018 елның 6 июлендәге 49-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергәнче гамәлдә булган редакциясендә) 3 һәм 4 статьялары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданин Р.Х. Ибәтуллин шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки ул «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданин Р.Х. Ибәтуллинга һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 20-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Н.Е. Мешковой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 1 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 2-ЗРТ «О парламентском контроле в Республике Татарстан»**

14 сентября 2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Н.Е Мешковой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Н.Е. Мешкова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 1 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 2-ЗРТ «О парламентском контроле в Республике Татарстан» (далее также — Закон Республики Татарстан).

В соответствии с оспариваемым положением Государственный Совет Республики Татарстан в порядке, установленном законами Республики Татарстан, осуществляет контроль за обеспечением соблюдения Кабинетом Министров Республики Татарстан и органами исполнительной власти Республики Татарстан установленных сроков принятия нормативных правовых актов, разработка и принятие которых предусмотрены законами Республики Татарстан, а также за полнотой регулирования соответствующих правоотношений в целях выявления соответствующих пробелов.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница является инвалидом 2 группы по заболеванию, которое входит в Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный приказом Министерства здравоохранения Российской Федерации от 29 ноября 2012 года № 987н (ранее действовал Перечень, утвержденный постановлением Правительства Российской Федерации от 16 июня 2006 года № 378), и с 2009 года состоит на учете в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий по договору социального найма во внеочередном порядке. Однако жилое помещение до настоящего времени ей не предоставлено в связи с тем, что категории граждан, к которой она относится, должна предоставляться жилищная субсидия (единовременная денежная выплата) на приобретение жилого помещения.

Гражданка Н.Е. Мешкова указывает, что она обращалась в государственные органы исполнительной власти Республики Татарстан, в органы местного самоуправления, а также в судебные

органы по вопросам предоставления ей жилого помещения по договору социального найма, а также получения ею жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения. Однако на все ее обращения были получены отказы.

При этом, как отмечает заявительница, одним из условий получения вышеуказанной субсидии является признание инвалидов, страдающих тяжелыми формами хронических заболеваний, указанных в Перечне, нуждающимися в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования. В соответствии с пунктом 1 статьи 3 Закона Республики Татарстан от 16 марта 2015 года № 13-ЗРТ «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования» установление порядка учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования в Республике Татарстан, в том числе порядка принятия на этот учет, отказа в принятии на него и снятия с него, относится к полномочиям Кабинета Министров Республики Татарстан в области жилищных отношений.

Между тем, как подчеркивает заявительница, на момент ее обращения в Конституционный суд Республики Татарстан такой порядок Кабинетом Министров Республики Татарстан не был принят, тогда как согласно части 2 статьи 18 названного Закона Республики Татарстан Кабинету Министров Республики Татарстан надлежало принять нормативные правовые акты, обеспечивающие реализацию данного Закона Республики Татарстан, в течение трех месяцев со дня вступления его в силу.

В этой связи гражданка Н.Е. Мешкова обратилась в Государственный Совет Республики Татарстан с просьбой сообщить, проводился ли парламентом в соответствии с Законом Республики Татарстан «О парламентском контроле в Республике Татарстан» контроль в отношении реализации пункта 1 статьи 3 и части 2 статьи 18 Закона Республики Татарстан «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования», поскольку в открытых для населения информационных источниках сведений о проведении парламентского контроля она не обнаружила.

По мнению заявительницы, это связано с тем, что оспариваемая норма не устанавливает порядок осуществления такого контроля, а также порядок ознакомления с результатами проведения парламентского контроля и не обеспечивает их общедоступность, что нарушает ее конституционные права и свободы.

На основании изложенного гражданка Н.Е. Мешкова просит Конституционный суд Республики Татарстан признать часть 1 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 2-ЗРТ «О парламентском контроле в Республике Татарстан» не соответствующей статьям 2, 28 (части первая и вторая), 48 (части

первая и вторая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Правовую основу осуществления парламентского контроля в Республике Татарстан, согласно статье 2 оспариваемого Закона Республики Татарстан, составляют Конституция Российской Федерации, Федеральный закон от 6 октября 1999 года № 184-ФЗ «Об общих принципах организации законодательных (представительных) и исполнительных органов государственной власти субъектов Российской Федерации», иные федеральные законы, Конституция Республики Татарстан, данный Закон, иные законы Республики Татарстан. Указанный Федеральный закон в подпункте «а» пункта 4 статьи 5 устанавливает, что законодательный (представительный) орган государственной власти субъекта Российской Федерации в пределах и формах, установленных конституцией (уставом) субъекта Российской Федерации и законами субъекта Российской Федерации, осуществляет наряду с другими уполномоченными на то органами в том числе контроль за соблюдением и исполнением законов субъекта Российской Федерации. Аналогичные положения содержатся в статье 81 Конституции Республики Татарстан.

Оспариваемое правовое положение, закрепляя за Государственным Советом Республики Татарстан полномочие по осуществлению контроля за обеспечением соблюдения Кабинетом Министров Республики Татарстан и органами исполнительной власти Республики Татарстан установленных сроков принятия нормативных правовых актов, разработка и принятие которых предусмотрены законами Республики Татарстан, направлено на защиту конституционных прав и свобод человека и гражданина, укрепление законности и правопорядка, а также на повышение эффективности системы государственного управления.

Обжалуемую норму необходимо рассматривать в системном единстве с другими положениями оспариваемого Закона Республики Татарстан, регламентирующими формы парламентского контроля. Так, согласно части 2 статьи 9 данного Закона Республики Татарстан Кабинет Министров Республики Татарстан ежеквартально не позднее чем через 30 дней со дня окончания квартала направляет в Государственный Совет Республики Татарстан информацию о ходе разработки и предполагаемых сроках принятия нормативных правовых актов, разработка и принятие которых предусмотрены законами Республики Татарстан. Государственный Совет Республики Татарстан в рамках полномочий, предусмотренных статьей 8 Закона Республики Татарстан «О парламентском контроле в Республике Татарстан», вправе заслушивать ответственных должностных лиц Кабинета Министров Республики Татарстан о данной работе. Из этого следует, что установленные законодательством формы парламентского контроля позволяют требовать от органов исполнительной власти исполнения ими своей прямой обязанности по принятию подзаконных актов, направленных на формирование механизма реализации законов, что призвано повысить эффективность правотворческого процесса в Республике Татарстан.

Применительно к рассматриваемому делу следует отметить, что Комитетом Государственного Совета Республики Татарстан по социальной политике 14 марта 2018 года было принято постановление «О реализации законодательства в части обеспечения инвалидов жилыми помещениями», текст которого во исполнение законодательно закрепленного принципа гласности размещен на официальном сайте Государственного Совета Республики Татарстан. Согласно пункту 3 данного постановления Кабинету Министров Республики Татарстан было рекомендовано принять меры по обеспечению реализации статьи 8.2 Закона Республики Татарстан «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан», в том числе в части установления порядка учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования. Во исполнение пункта 1 статьи 3 Закона Республики Татарстан «О реализации прав граждан на предоставление им жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования» постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 7 июня 2018 года № 432 утвержден Порядок учета граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, регламентирующий механизм принятия на учет граждан, нуждающихся в предоставлении жилых помещений по договорам найма жилых помещений жилищного фонда социального использования, отказа в принятии на такой учет, а также снятия с учета.

Таким образом, оспариваемая часть 1 статьи 9 Закона Республики Татарстан «О парламентском контроле в Республике Татарстан» принята во исполнение федерального и республиканского законодательства, сама по себе не может рассматриваться как нарушающая конституционные права граждан, в том числе заявительницы, и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы не является допустимой.

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Н.Е. Мешковой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 1 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 12 января 2016 года № 2-ЗРТ «О парламентском контроле в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными

требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Н.Е. Мешковой, в Государственный Совет Республики Татарстан и Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 21-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.Е. Мешкова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
14 сентябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Н.Е. Мешкова шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Н.Е. Мешкова «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 9 статьясындагы 1 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган нигезләмә буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы законнары белән билгеләнгән тәртиптә әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны кабул итүнең билгеләнгән срокларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан үтәлешен тәэмин итүне, шулай ук тиешле кимчелекләрне ачыклау максатларында тиешле хокук мөнәсәбәтләрен җайга салуның тулылыгын тикшереп тора.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә (элек Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 16 июнендәге 378 номерлы карары белән расланган Исемлек гамәлдә булган) кергән авыру буенча 2 төркем инвалиды һәм ул 2009 елдан торак шартларын чираттан тыш тәртиптә социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак исәптә тора. Ләкин торак урын әлеге вакытка кадәр аңа бирелмәгән, чөнки ул караган гражданнар категориясенә торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) бирелергә тиеш.

Гражданка Н.Е. Мешкова күрсәткәнчә, ул Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең дәүләт органнарына, җирле

үзидарә органнарына, шулай ук суд органнарына аңа социаль наем шартнамәсе буенча торак урын бирү, шулай ук торак урын сатып алу өчен торак субсидиясе (бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү) алу мәсьәләләре буенча мөрәҗәгать иткән. Ләкин аның бөтен мөрәҗәгатьләре кире кагылган.

Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, әлеге субсидияне алуның бер шарты булып Исемлектә күрсәтелгән авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылуы тора. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 16 мартындагы 13-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пункты нигезендә Татарстан Республикасында социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен, шул исәптән әлеге исәпкә кую, исәпкә куюдан баш тарту, аннан төшереп калдыру тәртибен билгеләү торак мөнәсәбәтләре өлкәсендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләтләренә керә.

Шул ук вакытта, мөрәҗәгать итүче ассызыклаганча, ул Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткән моментка андый тәртип Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан кабул ителмәгән булган, ә аталган Татарстан Республикасы Законының 18 статьясындагы 2 өлеше буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Татарстан Республикасы Законы үз көченә кергән көннән башлап өч ай эчендә аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш булган.

Шуңа бәйле рәвештә гражданка Н.Е. Мешкова парламент тарафыннан «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пунктын һәм 18 статьясындагы 2 өлешен гамәлгә ашыру мөнәсәбәтендә тикшерү уздырылган булу-булмавын хәбәр итүне сорап Татарстан Республикасы Дәүләт Советына мөрәҗәгать иткән, чөнки ул халык өчен ачык булган мәгълүмат чыганакларында парламент контроле үткәрелгән булуы турында мәгълүмат тапмаган.

Мөрәҗәгать итүче фикеренчә, бу шуңа бәйле: дәгъвалана торган норма шундый тикшерү үткәрү тәртибен, шулай ук уздырылган парламент контроле нәтиҗәләре белән танышу тәртибен билгеләми һәм алардан һәркемнең файдалана алуын тәэмин итми, бу исә аның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Н.Е. Мешкова Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Зако-

нының 9 статьясындагы 1 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 48 (беренче һәм икенче өлешләр) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Парламент контролен гамәлгә ашыруның хокукый нигезен, дәгъвалана торган Татарстан Республикасы Законының 2 статьясы буенча, Россия Федерациясе Конституциясе, «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон, башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасының бүтән законнары тәшкил итә. Күрсәтелгән Федераль закон 5 статьясындагы 4 пунктының «а» пунктчасында билгеләгәнчә, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органы Россия Федерациясе субъекты конституциясе (уставы) һәм Россия Федерациясе субъекты законнары билгеләгән чикләрдә һәм рәвешләрдә шуңа вәкаләтле башка органнар белән беррәттән шул исәптән Россия Федерациясе субъекты законнарының үтәлешен һәм башкарылуын тикшереп тора. Тиңдәш нигезләмәләр Татарстан Республикасы Конституциясенең 81 статьясында урын алган.

Дәгъвалана торган хокукый нигезләмә, әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны кабул итүнең билгеләнгән срокларының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары тарафыннан үтәлешен тәэмин итүне тикшереп тору вәкаләтен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына беркетеп, кеше һәм гражданның конституциячел хокукларын һәм ирекләрен яклауга, законлылык һәм хокук тәртибен ныгытуга, шулай ук дәүләт идарәсе системасы нәтиҗәлелеген арттыруга юнәлдерелгән.

Дәгъвалана торган норманы дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законының парламент контроле рәвешләрен регламентлаштыра торган башка нигезләмәләре белән системалы берлектә карарга кирәк. Шулай, әлеге Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 2 өлеше буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты квартал тәмамланган көннән алып 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Дәүләт Советына әзерләве һәм кабул итүе Татарстан Республикасы законнары белән каралган норматив хокукый актларны әзерләү барышы һәм аларны кабул итүнең күз алдында тотылган сроклары турында мәгълүмат җибәрә. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» Татарстан Республикасы Законының 8 статьясы белән каралган вәкаләтләр кысаларында әлеге эш турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының җаваплы вазыйфаи затларын тыңларга хокуклы. Моннан чыгып, закон белән билгеләнгән парламент контроле рәвешләре башкарма хакимият органнарыннан законнарның гамәлгә ашырылу механизмын оештыруга юнәлдерелгән законга буйсыну-

лы актлар кабул итү буенча үзләренең турыдан-туры бурычын үтәүне таләп итәргә рөхсәт итәләр, бу исә Татарстан Республикасында хокук чыгару процессының нәтиҗәлелеген арттыруга китерә.

Тикшерелә торган эшкә карата шуны билгеләп үтәргә кирәк: Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Социаль сәясәт комитеты тарафыннан 2018 елның 14 мартында «Инвалидларны торак урыннар белән тәэмин итү өлешендә законнарны гамәлгә ашыру турында» карары кабул ителгән, закон белән беркетелгән хәбәрдарлык принцибын үтәү йөзеннән аның тексты Татарстан Республикасы Дәүләт Советының рәсми сайтында урнаштырылган. Әлеге карарның 3 пункты буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына «Татарстан Республикасында халыкка адреслы социаль ярдәм күрсәтү турында» Татарстан Республикасы Законының 8.2 статьясын гамәлгә ашыруны, шул исәптән социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен билгеләү өлешендә, тәэмин итү чараларын күрергә тәкъдим ителгән. «Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча гражданнарның торак урыннары алу хокукларын гамәлгә ашыру турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 1 пунктын үтәү йөзеннән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә кую, андый исәпкә куюдан баш тарту, шулай ук исәптән төшереп калдыру механизмын регламентлаштыра торган Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе расланган.

Шулай итеп, «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы дәгъвалана торган 1 өлеше федераль һәм республика законнарын үтәү йөзеннән кабул ителгән, үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Татарстан Республикасында парламент контроле турында» 2016 елның 12 гыйнварындагы 2-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясындагы 1 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Н.Е. Мешкова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Н.Е. Мешковага, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 21-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**о прекращении производства по жалобе гражданки Р.М. Шайхразиевой на нарушение ее конституционных прав и свобод решением Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от 12 августа 2014 года № 209 «Об отмене решения VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» и решения XV сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 22 августа 2012 года № 102 «О внесении изменений в решение VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет»**

18 сентября 2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании сообщение судьи-докладчика Э.М. Мустафиной о прекращении производства по жалобе гражданки Р.М. Шайхразиевой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Р.М. Шайхразиева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод решением Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от 12 августа 2014 года № 209 «Об отмене решения VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» и решения XV сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 22 августа 2012 года № 102 «О внесении изменений в решение VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет».

Согласно Положению о порядке выплаты муниципальному служащему и выборному должностному лицу органа местного самоуправления Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет, утвержденному решением Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от

28 июня 2011 года № 34 (в редакции решения Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от 22 августа 2012 года № 102), муниципальному служащему при увольнении с муниципальной службы в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет выплачивалось единовременное поощрение. Обжалуемым решением Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан право муниципального служащего на получение единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет было отменено в связи с низким исполнением доходной части бюджета района.

По мнению гражданки Р.М. Шайхразиевой, отмена оспариваемым актом права муниципального служащего на получение рассматриваемого единовременного поощрения нарушает ее конституционные права, поскольку при осуществлении органами публичной власти правового регулирования недопустимо вносить произвольные изменения, могущие привести к ограничению законных прав и интересов граждан, обладающих официально признанным статусом. Кроме того, она указывает, что обжалуемое решение Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан не было официально опубликовано для всеобщего сведения, чем оно также нарушает ее конституционные права, поскольку заявительница, продолжая работать, не знала об отмене права на получение указанного единовременного поощрения.

На основании изложенного гражданка Р.М. Шайхразиева просит Конституционный суд Республики Татарстан признать решение Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от 12 августа 2014 года № 209 «Об отмене решения VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» и решения XV сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 22 августа 2012 года № 102 «О внесении изменений в решение VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» не соответствующим статьям 2, 13, 24 (часть третья), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 54 (часть первая) и 58 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан.

2. Конституционный суд Республики Татарстан определением от 9 июля 2018 года № 13-О принял жалобу гражданки Р.М. Шайхразиевой к рассмотрению. Однако 7 сентября 2018 года гражданка Р.М. Шайхразиева обратилась в Конституционный суд Республики Татарстан с заявлением об отзыве своей жалобы.

В соответствии со статьей 47 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» обращение в Конституционный суд Республики Татарстан может быть отозвано

заявителем до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан. В случае отзыва обращения производство по делу прекращается.

Поскольку заявительница отозвала свое обращение до начала рассмотрения дела в заседании Конституционного суда Республики Татарстан, производство по данной жалобе подлежит прекращению.

Исходя из изложенного, руководствуясь статьей 47, частями первой и пятой статьи 66, статьей 72 и частью первой статьи 73 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Производство по жалобе гражданки Р.М. Шайхразиевой на нарушение ее конституционных прав и свобод решением Совета Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан от 12 августа 2014 года № 209 «Об отмене решения VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» и решения XV сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 22 августа 2012 года № 102 «О внесении изменений в решение VI сессии Совета Муслюмовского муниципального района II созыва от 28 июня 2011 года № 34 «Об утверждении Положения о порядке выплаты муниципальному служащему Муслюмовского муниципального района единовременного поощрения в связи с выходом на государственную пенсию за выслугу лет» прекратить в связи с отзывом заявительницей данной жалобы.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Р.М. Шайхразиевой и в Совет Муслюмовского муниципального района Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 22-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарын һәм «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2012 елның 22 августындагы XV сессиясенең 102 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 12 августындагы 209 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.М. Шәйхразиева шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында**

2018 ел
18 сентябрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында гражданка Р.М. Шәйхразиева шикаяте буенча эш башкаруны туктату турында судья Э.М. Мостафина мәгълүматын тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Р.М. Шәйхразиева «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарын һәм «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2012 елның 22 августындагы XV сессиясенең 102 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 12 августындагы 209 номерлы карары

белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге 34 номерлы карары (Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2012 елның 22 августындагы 102 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Мөслим муниципаль районы җирле үзидарә органының муниципаль хезмәткәренә һәм сайланулы вазыйфаи затына тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмә буенча тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәттән җибәрелгәч, муниципаль хезмәткәргә бер тапкыр бирелә торган акча түләнгән. Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының дәгъвалана торган карары белән муниципаль хезмәткәрнең тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча алуга хокукы район бюджетының керем өлешенең түбән үтәлеше аркасында юкка чыгарылган.

Гражданка Р.М. Шәйхразиева фикеренчә, дәгъвалана торган акт белән муниципаль хезмәткәрнең карала торган бер тапкыр бирелә торган акча алуга хокукын юкка чыгару аның конституциячел хокукларын боза, чөнки гавами хакимият органнары тарафыннан хокукый җайга салу башкарылганда рәсми статуска ия булган гражданнарның законлы хокукларын һәм мәнфәгатьләрен чикләүгә китерә ала торган нигезсез үзгәрешләр кертергә рөхсәт ителми. Моннан тыш, ул күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының дәгъвалана торган карары гомуми танышу өчен рәсми рәвештә басылып чыкмаган, шуның белән ул аның конституциячел хокукларын шулай ук боза, чөнки мөрәҗәгать итүче эшләгән вакытта күрсәтелгән бер тапкыр бирелә торган акча алуга хокукның юкка чыгарылуы турында белмәгән.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.М. Шәйхразиева Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарын һәм «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2012 елның 22 августындагы XV сессиясенең 102 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 12 августындагы 209 номерлы карарын

Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 13, 24 (өченче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш) һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституция суды 2018 елның 9 июлендәге 13-О номерлы билгеләмәсе белән гражданка Р.М. Шәйхразиева шикаятен карауга кабул итте. Ләкин 2018 елның 7 сентябрендә гражданка Р.М. Шәйхразиева Татарстан Республикасы Конституция судына үз шикаятен кире алу турында гариза белән мөрәҗәгать итте.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына бирелгән мөрәҗәгать Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы ук мөрәҗәгать итүче тарафыннан кире алынырга мөмкин. Мөрәҗәгать кире алынган очракта эшне карау туктатыла.

Мөрәҗәгать итүче үз шикаятен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышында эшне карый башлаганчы кире алганга күрә, әлеге шикаять буенча эш башкару туктатылырга тиеш.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 47 статьясына, 66 статьясындагы беренче һәм бишенче өлешләренә, 72 статьясына һәм 73 статьясындагы беренче өлешенә таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарын һәм «Мөслим муниципаль районының муниципаль хезмәткәренә тиешле елларны эшләгән өчен дәүләт пенсиясенә чыгуга бәйле рәвештә бер тапкыр бирелә торган акча түләү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2011 елның 28 июнендәге VI сессиясенең 34 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» II чакырылыш Мөслим муниципаль районы Советының 2012 елның 22 августындагы XV сессиясенең 102 номерлы карарын гамәлдән чыгару хакында» Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советының 2014 елның 12 августындагы 209 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Р.М. Шәйхразиева шикаяте буенча эш башкаруны, мөрәҗәгать итүченең әлеге шикаятьне кире алуы сәбәпле, туктатырга.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.М. Шәйх-

разиевага һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 22-О

Татарстан Республикасы Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Н.Е. Мешковой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 3 статьи 8 и частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 3 июля 2010 года № 49-ЗРТ «О мониторинге законов Республики Татарстан»**

18 сентября 2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Э.М. Мустафиной, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Н.Е. Мешковой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Н.Е. Мешкова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 3 статьи 8 и частью 3 статьи 9 Закона Республики Татарстан от 3 июля 2010 года № 49-ЗРТ «О мониторинге законов Республики Татарстан».

В силу положений части 3 статьи 8 оспариваемого Закона Республики Татарстан по результатам анализа данных наблюдения за реализацией законов Республики Татарстан комитет Государственного Совета Республики Татарстан (далее — комитет Государственного Совета) готовит информацию о ходе реализации законов Республики Татарстан, в которой раскрываются предмет и основа наблюдения за реализацией законов Республики Татарстан, показатели реализации законов Республики Татарстан, обобщающие выводы.

Часть 3 статьи 9 вышеуказанного Закона Республики Татарстан устанавливает, что по результатам оценки эффективности реализации законов Республики Татарстан комитет Государственного Совета принимает решение об итогах мониторинга, в котором при необходимости указываются рекомендации комитета по повышению эффективности реализации законов Республики Татарстан.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница является инвалидом 2 группы по заболеванию, которое входит в Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный постановлением Правительства Российской Федерации от 16 июня 2006 года № 378 (в настоящее время действует Перечень тяжелых форм хронических заболеваний, при которых невозможно совместное проживание граждан в одной квартире, утвержденный приказом Министерства здравоохранения Российской Федерации от 29 ноября 2012 года № 987н), и с 2009 года состоит на учете в качестве нуждающейся в улучшении жилищных условий по договору социального найма во внеочередном порядке, однако жилое помещение до настоящего

времени ей не предоставлено. В решении жилищного вопроса ей было отказано в связи с тем, что категории граждан, к которой она относится, должна предоставляться жилищная субсидия (единовременная денежная выплата) на приобретение жилого помещения в соответствии со статьей 8.2 Закона Республики Татарстан от 8 декабря 2004 года № 63-ЗРТ «Об адресной социальной поддержке населения в Республике Татарстан».

Гражданка Н.Е. Мешкова указывает, что она обращалась в органы исполнительной власти Республики Татарстан, в органы местного самоуправления, а также в судебные органы по вопросам предоставления ей жилого помещения по договору социального найма, а также получения ею жилищной субсидии (единовременной денежной выплаты) на приобретение жилого помещения. Однако на все ее обращения были получены отказы.

**«Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 1 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Р.Ф. Айнуллова шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
2 октябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Р.Ф. Айнуллова шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) 1 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата шикаять белән үзенең балигъ булмаган кызы мәнфәгатьләрендә гражданка Р.Ф. Айнуллова мөрәҗәгать итте.

Дәгъвалана торган нигезләмә белән шул билгеләнгән: әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексының 51 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалидларга, шулай ук әлеге исемлектә күрсәтелгән хроник авыруларның авыр формалары белән авырган инвалид балалары булган, билгеләнгән тәртиптә социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ дип танылган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гаиләләргә (алга таба — гражданнар категорияләре) Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү механизмын билгели.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Р.Ф. Айнуллованың

балигъ булмаган кызы — Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгының 2012 елның 29 ноябрендәге 987н номерлы боерыгы белән расланган Гражданнарның бер фатирда бергә яшәүләре мөмкин булмаган хроник авыруларның авыр формалары исемлегенә кергән авыр хроник авырудан интегүче инвалид. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе башлыгының 2016 елның 20 июлендәге күрсәтмәсе белән мөрәҗәгать итүче кызы белән бергә торак шартларын чираттан тыш тәртиптә социаль наем шартнамәсе буенча яхшыртуга мохтаҗ буларак исәпкә куелган. Ләкин, ул күрсәткәнчә, торак урын әлеге вакытка кадәр аларга бирелмәгән һәм торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бүленмәгән.

Шул ук вакытта мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, 2018 елның 7 июнендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе расланган, ләкин Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты тарафыннан расланган социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарның исәбен алып бару тәртибе булмаганга күрә, торак субсидиясен (бер тапкыр акчалата түләү) алырга мөмкин түгел. Ул санаганча, дәгъвалана торган Тәртип социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибен дә җайга салса, авыр хроник авырулардан интегүче инвалидларның торак субсидиясенә (бер тапкыр акчалата түләүгә) хокуклары инде гамәлгә ашырылырга мөмкин иде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Р.Ф. Айнуллова дәгъвалана торган норма үзенең дә, аның балигъ булмаган кызының да конституциячел хокукларын боза дип саный һәм Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 13, 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 54 (беренче өлеш), 55 һәм 58 (икенче өлеш) статьяларына каршы килә дип тануны сорый.

2. «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең

гражданка Р.Ф. Айнуллова тарафыннан дәгъва белдерелә торган 1 пункты берничә тапкыр Татарстан Республикасы Конституция судының карау предметын тәшкил иткән иде инде. Татарстан Республикасы Конституция суды үзенең 2018 елның 28 июнендәге 9-О һәм 10-О номерлы билгеләмәләрендә шуны билгеләп үтте: дәгъвалана торган Тәртипнең 1 пункты социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ булган, 2005 елның 1 гыйнварыннан соң исәпкә куелган гражданнарның аерым категорияләренә торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү буенча гомуми нигезләмәләрдән тора. Шул ук вакытта карала торган норма асылда дәгъвалана торган Тәртипнең хокукый җайга салу предметын гына билгели, әмма күрсәтелгән субсидияне бирү механизмының конкрет эчтәлеген ачыкламый, шуңа күрә дә үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең конституциячел хокукларын шикаятьтә күрсәтелгән аспектта боза торган буларак санала алмый.

Моннан тыш, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 7 июнендәге 432 номерлы карары белән Социаль файдаланудагы торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча торак урыннар бирелүгә мохтаҗ гражданнарны исәпкә алу тәртибе расланган. Аның нигезләмәләренең турыдан-туры дәгъвалана торган Тәртиптә, шул исәптән 1 пунктта чагылыш табылмавы факты, шуңа гражданка Р.Ф. Айнуллова сылтама ясый да, шулай ук үзеннән-үзе аның конституциячел хокукларын бозу буларак карала һәм әлеге норма эчтәлегенең билгесезлеге турында раслый алмый.

Шулай итеп, дәгъвалана торган хокукый җайга салу Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына бирелгән вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән, гамәлдәге законнар таләпләренә җавап бирә һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте карала алмый.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Инвалидларның аерым категорияләренә Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның

18 апрелендәге 236 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән торак урын сатып алуга торак субсидиясе (бер тапкыр акчалата түләү) бирү тәртибенең 1 пункты белән конституциячел хокуклар һәм ирекләр бозылуга карата гражданка Р.Ф. Айнуллова шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Р.Ф. Айнулловага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 30-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**по жалобе гражданки О.Н. Меркурьевой на нарушение ее конституционных прав и свобод положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II, а также пунктом 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250**

29 октября 2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки О.Н. Меркурьевой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка О.Н. Меркурьева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II, а также пунктом 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250 (далее также — Порядок).

Согласно пункту 4 раздела I Порядка предоставление гражданам бесплатного земельного участка для осуществления индивидуального жилищного строительства, дачного строительства, ведения личного подсобного хозяйства (приусадебный земельный участок), садоводства или огородничества производится в порядке очередности не позднее одного года с даты их включения в списки, за исключением случая, предусмотренного пунктом 7 раздела II данного Порядка.

Пункт 7 раздела II указанного Порядка устанавливает, что при отказе заявителя от участия в процедуре выбора земельного участка или при его отказе от земельного участка в процессе процедуры выбора земельного участка либо при неприбытии заявителя для участия в процедуре выбора земельного участка по неуважительной причине заявлению присваивается статус «Отказ заявителя». Отказ заявителя от участия в процедуре выбора земельного участка или его отказ от выбора земельного участка в процессе процедуры выбора земельного участка либо неприбытие заявителя для участия в процедуре выбора земельного участка по неуважительной причине оформляется актом (приложения № 2 и 3) и протоколом комиссии.

В соответствии с пунктом 1 раздела II названного Порядка Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (далее так-

же — Комитет) назначает место, дату и время проведения процедуры выбора земельных участков и определяет граждан для участия в указанной процедуре в порядке их очередности и в зависимости от количества сформированных земельных участков; не позднее чем за две недели до проведения процедуры выбора земельного участка граждане в порядке их очередности, определенной Комитетом, заказным письмом с уведомлением о вручении извещаются о месте, дате и времени ее проведения; после направления заявителю извещения заявлению присваивается статус «Участие в выборе земельного участка».

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница, имеющая троих детей, в соответствии с земельным законодательством обладает правом на предоставление ей земельного участка из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность бесплатно. В 2013 году гражданка О.Н. Меркурьева подала заявление для реализации этого права и была внесена в список граждан, имеющих право на получение земельного участка для осуществления индивидуального жилищного строительства. Между тем земельный участок семье не был предоставлен, несмотря на то, что в соответствии с пунктом 13 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан он должен быть передан в порядке очередности не позднее одного года с даты включения в списки, за исключением случая, предусмотренного пунктом 15 этой же статьи, согласно которому при троекратном отказе от выбора земельного участка либо троекратной неявке на процедуру выбора земельного участка гражданин исключается из списка.

Заявительница указывает, что в июне 2017 года она была приглашена на процедуру выбора земельного участка. Гражданка О.Н. Меркурьева отказалась от предложенного земельного участка, поскольку земельный участок ей был предложен не в границах города Казани, а на территории муниципального района. В ходе процедуры выбора земельного участка, как она отмечает, ей было сообщено, что в случае отказа от предложенного земельного участка в соответствии с оспариваемыми положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II Порядка органы местного самоуправления будут освобождены от обязанности предоставить земельный участок не позднее одного года. В этой связи гражданка О.Н. Меркурьева была вынуждена подписать акт выбора земельного участка, однако впоследствии от земельного участка отказалась и не представила документы для завершения оформления процедуры.

По утверждению заявительницы, Земельный кодекс Республики Татарстан предусматривает в качестве единственно возможного отступления от предоставления гражданам земельных участков в порядке очередности не позднее одного года с даты включения в списки их троекратный отказ от выбора земельного участка либо троекратную неявку на процедуру выбора земельного участка.

Оспариваемые же положения пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II Порядка устанавливают в качестве возможного отступления от предоставления гражданам земельных участков в

порядке очередности не позднее одного года с даты включения в списки их однократный отказ от выбора земельного участка либо однократную неявку на процедуру выбора земельного участка. Следовательно, по мнению гражданки О.Н. Меркурьевой, оспариваемые нормы фактически вынуждают согласиться на земельный участок на первом же предложенном выборе, поскольку отказ сразу повлечет освобождение органа местного самоуправления от публично-правового обязательства по предоставлению земельного участка в течение одного года.

Абзацы второй и третий пункта 13 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан предусматривают, что органы местного самоуправления назначают место, дату и время проведения процедуры выбора земельных участков и определяют граждан для участия в указанной процедуре в соответствии с их очередностью и количеством сформированных земельных участков; не позднее чем за 14 дней до дня проведения процедуры выбора земельного участка граждане, определенные органом местного самоуправления, извещаются о месте, дате и времени ее проведения заказным письмом с уведомлением о вручении, телеграммой либо путем вручения им извещения под роспись.

Тем самым, как отмечает заявительница, республиканский законодатель четко и ясно установил, что место, дату и время проведения процедуры выбора земельных участков, а также граждан для участия в указанной процедуре определяют непосредственно органы местного самоуправления, не допуская при этом как передачи ими этих полномочий, так и принятия данных решений какими-либо учреждениями от их имени. Однако согласно оспариваемому пункту 1 раздела II Порядка место, дату, время проведения процедуры выбора земельных участков и граждан, в ней участвующих, определяет Комитет, который является муниципальным казенным учреждением, а не органом местного самоуправления.

Таким образом, по мнению гражданки О.Н. Меркурьевой, оспариваемые положения видоизменяют установленные Земельным кодексом Республики Татарстан условия предоставления земельных участков. Вместе с тем в соответствии со статьей 24 (часть вторая) Конституции Республики Татарстан деятельность органов местного самоуправления должна носить законный характер. Тем самым, как она полагает, обжалуемые нормы прямо противоречат конституционному принципу верховенства права, что влечет за собой и нарушение конституционных принципов равенства и справедливости.

На основании изложенного заявительница просит Конституционный суд Республики Татарстан признать положения пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II, а также пункт 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250, не соответствующими статьям 24 (часть вторая), 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая) и 38 (части первая и третья) Конституции Республики Татарстан.

2. Согласно статье 109 (часть четвертая) Конституции Республики Татарстан и части пятой статьи 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» Конституционный суд Республики Татарстан по жалобам на нарушение конституционных прав и свобод граждан и по запросам судов проверяет конституционность закона Республики Татарстан или его отдельных положений, нормативных правовых актов Президента и Кабинета Министров Республики Татарстан, а также органов местного самоуправления. В силу этого оспариваемый заявительницей нормативный правовой акт соответствует категории нормативных правовых актов, подведомственных Конституционному суду Республики Татарстан, и может быть рассмотрен на предмет его соответствия Конституции Республики Татарстан.

В соответствии с частью первой статьи 100 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» правом на обращение в Конституционный суд Республики Татарстан с жалобой на нарушение конституционных прав и свобод обладают граждане, права и свободы которых нарушены законом Республики Татарстан, нормативными правовыми актами Президента Республики Татарстан и Кабинета Министров Республики Татарстан, органов местного самоуправления, и их объединения.

Согласно статье 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба на нарушение законом Республики Татарстан или иным нормативным правовым актом конституционных прав и свобод допустима, если закон или иной нормативный правовой акт затрагивает конституционные права и свободы граждан; закон или иной нормативный правовой акт применен или подлежит применению в конкретном деле, рассмотрение которого завершено или начато в суде или ином органе. В этой связи приложенные к жалобе документы согласно части второй статьи 100 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» могут рассматриваться как подтверждающие применение обжалуемых положений при разрешении конкретного дела заявителя. Тем самым жалоба исходит от надлежащего заявителя, соответствует критериям ее допустимости, установленным статьей 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

При этом следует отметить, что гражданка О.Н. Меркурьева в своей жалобе ставит под сомнение конституционность пункта 1 раздела II Порядка в части правомерности определения Комитета земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани в качестве уполномоченного органа по реализации процедуры предоставления гражданам бесплатного земельного участка, поскольку, по ее мнению, он не является органом местного самоуправления. В этой связи Конституционный суд Республики Татарстан полагает необходимым отметить следующее.

В соответствии со статьей 34 Федерального закона от 6 октября 2003 года № 131-ФЗ «Об общих принципах организации местного самоуправления в Российской Федерации», статьей 21 Закона

Республики Татарстан от 28 июля 2004 года № 45-ЗРТ «О местном самоуправлении в Республике Татарстан» структуру органов местного самоуправления составляет в том числе местная администрация (исполнительно-распорядительный орган муниципального образования).

Согласно взаимосвязанным положениям статьи 38 и части 3 статьи 39 Устава муниципального образования города Казани, утвержденного решением представительного органа муниципального образования города Казани от 17 декабря 2005 года № 3-5, Исполнительный комитет муниципального образования города Казани является исполнительно-распорядительным органом местного самоуправления города Казани, наделенным полномочиями по решению вопросов местного значения, а также по осуществлению отдельных государственных полномочий, переданных органам местного самоуправления города Казани федеральными законами и законами Республики Татарстан, в структуру которого входят территориальные и отраслевые (функциональные) органы.

К числу отраслевых (функциональных) органов согласно решению Казанской городской Думы от 6 декабря 2010 года № 4-2 «О структуре Исполнительного комитета муниципального образования города Казани» относится Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани.

Решением Казанской городской Думы от 29 декабря 2010 года № 20-3 было утверждено Положение о муниципальном казенном учреждении «Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани», согласно которому Комитет является органом Исполнительного комитета муниципального образования города Казани, предметом и целью деятельности которого является выполнение управленческих функций в рамках своей компетенции в сфере реализации вопросов местного значения, а также переданных в установленном законодательством порядке государственных полномочий, определенных муниципальными правовыми актами органов местного самоуправления города Казани, а именно владения, пользования и распоряжения имуществом и имущественными правами, находящимися в муниципальной собственности города Казани.

Таким образом, оспариваемый заявительницей пункт 1 раздела II Порядка не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба заявительницы в этой части не является допустимой и не может быть принята к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

Что касается проверки конституционности положений пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II Порядка, то жалоба в этой части не содержит каких-либо оснований для отказа в принятии ее к рассмотрению Конституционным судом Республики Татарстан.

3. При подаче жалобы в Конституционный суд Республики Татарстан гражданкой О.Н. Меркурьевой заявлено ходатайство об освобождении ее от уплаты государственной пошлины, поскольку она является многодетной матерью и находится в тяжелом материальном положении.

В соответствии со статьей 42 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» при обращении в Конституционный суд Республики Татарстан государственная пошлина взимается в порядке, установленном федеральным законодательством. Из содержания пункта 3 статьи 333.23 Налогового кодекса Российской Федерации следует, что Конституционный суд Республики Татарстан, исходя из имущественного положения заявительницы и с учетом заявленного ходатайства, вправе освободить ее от уплаты государственной пошлины.

В связи с этим Конституционный суд Республики Татарстан считает возможным удовлетворить ходатайство гражданки О.Н. Меркурьевой и освободить ее от уплаты государственной пошлины.

На основании изложенного, руководствуясь частью пятой статьи 3, пунктом 1 части второй статьи 39, статьями 42, 44, частями первой и второй статьи 45, частью первой статьи 51, частью пятой статьи 66, статьями 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки О.Н. Меркурьевой в части, касающейся проверки конституционности пункта 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250, поскольку в этой части она не отвечает требованиям Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», в соответствии с которыми жалоба признается допустимой.

2. Принять к рассмотрению жалобу гражданки О.Н. Меркурьевой на нарушение ее конституционных прав и свобод положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250.

3. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

4. Удовлетворить ходатайство гражданки О.Н. Меркурьевой и освободить ее от уплаты государственной пошлины.

5. О принятом решении уведомить стороны — гражданку О.Н. Меркурьеву и Исполнительный комитет муниципального образования города Казани.

6. Назначить судьей-докладчиком по данному делу судью Конституционного суда Республики Татарстан А.Р. Шакараева.

7. Дату рассмотрения настоящего дела Конституционным судом Республики Татарстан установить в порядке очередности слушания дел в заседаниях Конституционного суда Республики Татарстан.

8. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 31-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләре, шулай ук II бүлегендәге 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка О.Н. Меркурьева шикаяте буенча**

2018 ел
29 октябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка О.Н. Меркурьева шикаятен алдан өйрәнгән судья А.Р. Шакараев бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка О.Н. Меркурьева Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең (алга таба шулай ук — Тәртип) I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләре, шулай ук II бүлегендәге 1 пункты белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты буенча гражданнарга индивидуаль торак төзелешен, дача төзелешен гамәлгә ашыру, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару (йорт янындагы җир кишәрлеге), бакчачылык яки яшелчәчелек белән шөгыльләнү өчен җир кишәрлеген бушлай бирү, әлеге Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты белән каралган очрактан тыш, аларны исемлекләргә керткән вакыттан алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә башкарыла.

Күрсәтелгән Тәртипнең II бүлегендәге 7 пункты шуны билгели: мөрәҗәгать итүче җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тартса яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тартса яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәсә, гаризага «Мөрәҗәгать итүче баш тартты» дигән статус бирелә. Мөрәҗәгать итүченең җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашудан баш тартуы яки җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында җир кишәрлегеннән баш тартуы яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасында катнашуга җитди сәбәпләре булмаган килеш килмәве акт (2 нче һәм 3 нче кушымталар) һәм комиссия беркетмәсе белән рәсмиләштерелә.

Аталган Тәртипнең II бүлегендәге 1 пункты нигезендә Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты (алга таба шулай ук — Комитет) җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын үткәрүнең урынын, көнен һәм вакытын билгели һәм әлеге процедурада катнашу өчен гражданнарны аларның чиратлары тәртибендә һәм булдырылган җир кишәрлекләре санынннан чыгып билгели; җир кишәрлеген сайлап алу процедурасын уздыруга ким дигәндә ике атна кала гражданнарга Комитет тарафыннан билгеләнгән үз чиратлары тәртибендә тапшырылуы турында хәбәр ителә торган заказлы хат белән аны уздыру урыны, көне һәм вакыты турында хәбәр ителә; мөрәҗәгать итүчегә хәбәрнамә җибәрелгәннән соң гаризага «Җир кишәрлеген сайлауда катнашу» дигән статус бирелә.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, өч баласы булган мөрәҗәгать итүче җир законнары нигезендә дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге җирләрдән җир кишәрлеген милеккә түләүсез алу хокукына ия. 2013 елда гражданка О.Н. Меркурьева әлеге хокукны тормышка ашыру өчен гариза биргән һәм индивидуаль торак төзелешен гамәлгә ашыру өчен җир кишәрлеге алуга хокукы булган гражданнар исемлегенә кертелгән. Шул ук вакытта җир кишәрлеге Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 13 пункты нигезендә, әлеге статьяның 15 пунктында каралган очрактан тыш (аның буенча җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тарткан яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килми калган очракта, граждан исемлектән төшереп калдырыла), исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә тапшырылырга тиеш булуга карамастан, ул гаиләгә бирелмәгән.

Мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, ул 2017 елның июнендә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына чакырылган булган. Гражданка О.Н. Меркурьева тәкъдим ителгән җир кишәрлегеннән баш тарткан, чөнки җир кишәрлеге аңа Казан шәһәре чикләрендә түгел, ә муниципаль район территориясендә тәкъдим ителгән. Җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы барышында, ул билгеләгәнчә, аңа шул хәбәр ителгән: тәкъдим ителгән җир кишәрлегеннән баш тарткан очракта, Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының дәгъвалана торган нигезләмәләре буенча җирле үзидарә органнары җир кишәрлеген бер елдан да соңга калмыйча бирү бурычыннан азат ителәчәкләр. Шуңа бәйле рәвештә гражданка О.Н. Меркурьева җир кишәрлеген сайлап алу актын имзаларга мәҗбүр булган, ләкин соңыннан җир кишәрлегеннән баш тарткан һәм процедураны рәсмиләштерүне тәмамлау өчен документлар тапшырмаган.

Мөрәҗәгать итүче раславы буенча, Татарстан Республикасы Җир кодексы гражданнарга җир кишәрлекләрен исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә бирүдән тайпылуның бердәнбер мөмкинлеге буларак аларның җир кишәрлеген сайлап алудан өч мәртәбә баш тар-

туын яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына өч мәртәбә килмәвен күздә тота.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пунктының дәгъвалана торган нигезләмәләре исә гражданнарга җир кишәрлекләрен исемлекләргә кергән көннән алып бер елдан да соңга калмыйча чиратлылык тәртибендә бирүдән тайпылу мөмкинлеге буларак аларның җир кишәрлеген сайлап алудан бер мәртәбә баш тартуын яисә җир кишәрлеген сайлап алу процедурасына бер мәртәбә килмәвен билгелиләр. Димәк, гражданка О.Н. Меркурьева фикере буенча, дәгъвалана торган нормалар фактта тәкъдим ителгән беренче сайлап алуда ук җир кишәрлегенә ризалашырга мәҗбүр итәләр, чөнки баш тарту шунда ук җирле үзидарә органын җир кишәрлеген бер ел эчендә бирү буенча гавами-хокукый бурычыннан азат итүгә китерәчәк.

Татарстан Республикасы Җир кодексының 32.1 статьясындагы 13 пунктының икенче һәм өченче абзацлары шуны күздә тоталар: җирле үзидарә органнары җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру урынын, көнен һәм вакытын билгелиләр һәм гражданнарны чиратлылык һәм табылган җир кишәрлекләре саны нигезендә әлеге процедурада катнашу өчен билгелиләр; җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән гражданнарга җир кишәрлеген сайлап алу процедурасы уздырыла торган көнгә кадәр 14 көннән дә соңга калмыйча аны уздыру урыны, көне, вакыты турында адресатка тапшырылуы хакында белдерү кәгазе булган заказлы хат, телеграмма җибәреп яисә аларга хәбәрнамәне имза алып тапшыру юлы белән хәбәр ителә.

Шуның белән, мөрәҗәгать итүче билгеләгәнчә, республика закон чыгаручысы җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру урынын, көнен һәм вакытын, шулай ук күрсәтелгән процедурада катнашу өчен гражданнарны турыдан-туры җирле үзидарә органнары билгели дип төгәл һәм ачык билгеләп, шул ук вакытта аларның әлеге вәкаләтләрен тапшыруны, шулай ук әлеге карарларны алар исеменнән нindидер учреждениеләр тарафыннан кабул итүне рөхсәт итмәгән. Ләкин Тәртипнең II бүлегендәге дәгъвалана торган 1 пункты буенча җир кишәрлекләрен сайлап алу процедурасын уздыру урынын, көнен, вакытын һәм анда катнашучы гражданнарны җирле үзидарә органы түгел, ә муниципаль казна учреждениесе булган Комитет билгели.

Шулай итеп, гражданка О.Н. Меркурьева фикере буенча, дәгъва белдерелә торган нигезләмәләр Татарстан Республикасы Җир кодексы билгеләгән җир кишәрлекләрен бирү шартларын үзгәртәләр. Шул ук вакытта Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 статьясы (икенче өлеш) нигезендә җирле үзидарә органнары эшчәнлеге законлы характерга ия булырга тиеш. Шуның белән, ул санаганча, дәгъвалана торган нормалар хокук өстенлеге конституциячел принцибына турыдан-туры каршы киләләр, бу исә тигезлек һәм гаделлек конституциячел принципларын бозуга да китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә мөрәҗәгать итүче Татарстан Рес-

публикасы Конституция судыннан Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләрен, шулай ук II бүлегендәге 1 пунктын Татарстан Республикасы Конституциясенең 24 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш) һәм 38 (беренче һәм өченче өлешләр) статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы (дүртенче өлеш) һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданнарның конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаятьләр буенча һәм судлар таләпләре буенча Татарстан Республикасы законының яисә аның аерым нигезләмәләренең, Татарстан Республикасы Президенты һәм Министрлар Кабинеты, шулай ук җирле үзидарә органнары норматив хокукый актларының конституциячеллеген тикшерә. Шуңа күрә мөрәҗәгать итүче дәгъва белдерә торган норматив хокукый акт Татарстан Республикасы Конституция суды карамагындагы норматив хокукый актлар категориясенә туры килә һәм Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә карап тикшерелергә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы беренче өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына конституциячел хокукларның һәм ирекләрнең бозылуына карата шикаять белән Татарстан Республикасы законы, Татарстан Республикасы Президентының һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының, җирле үзидарә органнарының норматив хокукый актлары белән хокуклары һәм ирекләре бозылган гражданнар һәм аларның берләшмәләре мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясы буенча Татарстан Республикасы законы яисә башка норматив хокукый акт белән конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылуына шикаять бирү мөмкин була, әгәр закон яисә башка норматив хокукый акт гражданнарның конституциячел хокукларына һәм ирекләренә кагылса; закон яисә башка норматив хокукый акт, аны карау судта яисә башка органда төгәлләнгән яки башланган конкрет эштә кулланылса яки кулланылырга тиеш булса. Шуңа бәйле рәвештә шикаятькә кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләре «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 100 статьясындагы икенче өлеше нигезендә дәгъвалана торган нигезләмәләрнең мөрәҗәгать итүченең конкрет эшен хәл иткәндә кулланылуын раслый торган итеп каралырга мөмкин. Шуның белән шикаять

тиешле мөрәҗәгать итүче тарафыннан бирелгән, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 101 статьясында билгеләнгән шикаять бирү таләпләренә туры килә.

Шул ук вакытта шуны билгеләп үтәргә кирәк: гражданка О.Н. Меркурьева үз шикаятендә Тәртипнең II бүлегендәге 1 пунктының конституциячеллеген Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитетын гражданнарга түләүсез җир кишәрлеге бирү процедурасын гамәлгә ашыру буенча вәкаләтле орган буларак билгеләүнең законлы булу-булмавы өлешендә шик астына куя, чөнки, аның фикеренчә, ул җирле үзидарә органы түгел. Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды түбәндәгене билгеләп үтүне кирәк дип саный.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 34 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 21 статьясы нигезендә җирле үзидарә органнары структурасын шул исәптән җирле администрация (муниципаль берәмлекнең башкарма-күрсәтмә органы) тәшкил итә.

Казан шәһәре муниципаль берәмлеге вәкиллекле органының 2005 елның 17 декабрендәге 3-5 номерлы карары белән расланган Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы һәм 39 статьясындагы 3 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү, шулай ук Казан шәһәре җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыру буенча вәкаләтләр йөкләнгән Казан шәһәре җирле үзидарәсенең башкарма-күрсәтмә органы булып тора, аның структурасына территориаль һәм тармак (функциональ) органнар керә.

Тармак (функциональ) органнар исәбенә «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты структурасы турында» Казан шәһәр Думасының 2010 елның 6 декабрендәге 4-2 номерлы карары буенча Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты керә.

Казан шәһәр Думасының 2010 елның 29 декабрендәге 20-3 номерлы карары белән «Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Җир һәм милек мөнәсәбәтләре комитеты» муниципаль казна учреждениесе турында нигезләмә расланган, аның буенча Комитет — Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты органы, аның эшчәнлегенең предметы һәм максаты булып җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне, шулай ук законнарда билгеләнгән тәртиптә тапшырылган Казан шәһәре җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актлары белән билгеләнгән дәүләт вәкаләтләрен, атап әйткәндә, Казан шәһәренең муниципаль милкендәге мөлкәтне һәм мөлкәти хокукларны биләү, алардан файдалану һәм алар белән эш итүне гамәлгә ашыру өлкәсендә

үз компетенциясе кысаларында идарә итү функцияләрен башкару тора.

Шулай итеп, Тәртипнең II бүлегендәге мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъвалана торган 1 пунктының Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа күрә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә мөрәҗәгать итүченең шикаяте әлеге өлештә бирелергә тиешсез була һәм Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга кабул ителә алмый.

Тәртипнең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләренең конституциячеллеген тикшерүгә килгәндә, шикаятьне әлеге өлештә Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан карауга алудан баш тарту өчен нинди дә булса нигезләр юк.

3. Татарстан Республикасы Конституция судына шикаять биргәндә, күпбалалы ана булганга һәм авыр матди хәлдә булганга күрә, гражданка О.Н. Меркурьева тарафыннан үзен дәүләт пошлинасын түләүдән азат итү турында үтенеч белдерелгән.

«Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 42 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Конституция судына мөрәҗәгать иткәндә дәүләт пошлинасы федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә алына. Россия Федерациясе Салым кодексының 333.23 статьясындагы 3 пункты эчтәлегеннән аңлашылганча, Татарстан Республикасы Конституция суды, мөрәҗәгать итүченең матди хәленнән чыгып һәм белдерелгән үтенечне исәпкә алып, аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә хокуклы.

Шуңа бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Конституция суды гражданка О.Н. Меркурьева үтенечен канәгатьләндерергә һәм аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә мөмкин дип саный.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы бишенче өлешенә, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 42, 44 статьяларына, 45 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 51 статьясындагы беренче өлешенә, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. Гражданка О.Н. Меркурьева шикаятен Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең II бүлегендәге 1 пунктының конституциячеллеген тикшерү өлешендә карауга алудан баш тартырга, чөнки әлеге өлештә ул «Татарстан Респуб-

ликасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының шикаять бирелергә мөмкин дигән таләпләренә җавап бирми.

2. Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2012 елның 6 сентябрендәге 6250 номерлы карары белән расланган Өч һәм аннан күбрәк балалары булган гражданнарга җир кишәрлекләре бирү турында карарлар кабул итү тәртибенең I бүлегендәге 4 пункты һәм II бүлегендәге 7 пункты нигезләмәләре белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка О.Н. Меркурьева шикаятен карауга кабул итәргә.

3. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

4. Гражданка О.Н. Меркурьева үтенечен канәгатьләндерергә һәм аны дәүләт пошлинасын түләүдән азат итәргә.

5. Кабул ителгән карар турында якларга — гражданка О.Н. Меркурьевага һәм Казан шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетына хәбәр итәргә.

6. Бу эш буенча докладчы судья итеп Татарстан Республикасы Конституция суды судьясы А.Р. Шакараевны билгеләргә.

7. Татарстан Республикасы Конституция суды тарафыннан әлеге эшне карап тикшерү көнен Татарстан Республикасы Конституция суды утырышларында эшләрне тыңлау чираты тәртибендә билгеләргә.

8. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 31-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**по жалобе гражданки Л.В. Рагимовой на нарушение ее конституционных прав и свобод положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II, а также пунктом 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250**

29 октября
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи А.Р. Шакараева, проводившего на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Л.В. Рагимовой,

**у с т а н о в и л :**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Л.В. Рагимова с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод положениями пункта 4 раздела I и пункта 7 раздела II, а также пунктом 1 раздела II Порядка принятия решений о предоставлении земельных участков гражданам, имеющим трех и более детей, утвержденного постановлением Исполнительного комитета муниципального образования города Казани от 6 сентября 2012 года № 6250 (далее также — Порядок).

Согласно пункту 4 раздела I Порядка предоставление гражданам бесплатного земельного участка для осуществления индивидуального жилищного строительства, дачного строительства, ведения личного подсобного хозяйства (приусадебный земельный участок), садоводства или огородничества производится в порядке очередности не позднее одного года с даты их включения в списки, за исключением случая, предусмотренного пунктом 7 раздела II данного Порядка.

Пункт 7 раздела II указанного Порядка устанавливает, что при отказе заявителя от участия в процедуре выбора земельного участка или при его отказе от земельного участка в процессе процедуры выбора земельного участка либо при неприбытии заявителя для участия в процедуре выбора земельного участка по неуважительной причине заявлению присваивается статус «Отказ заявителя». Отказ заявителя от участия в процедуре выбора земельного участка или его отказ от выбора земельного участка в процессе процедуры выбора земельного участка либо неприбытие заявителя для участия в процедуре выбора земельного участка по неуважительной причине оформляется актом (приложения № 2 и 3) и протоколом комиссии.

В соответствии с пунктом 1 раздела II названного Порядка Комитет земельных и имущественных отношений Исполнительного комитета муниципального образования города Казани (далее так-

же — Комитет) назначает место, дату и время проведения процедуры выбора земельных участков и определяет граждан для участия в указанной процедуре в порядке их очередности и в зависимости от количества сформированных земельных участков; не позднее чем за две недели до проведения процедуры выбора земельного участка граждане в порядке их очередности, определенной Комитетом, заказным письмом с уведомлением о вручении извещаются о месте, дате и времени ее проведения; после направления заявителю извещения заявлению присваивается статус «Участие в выборе земельного участка».

Как следует из жалобы и приложенных к ней копий документов, заявительница, имеющая троих детей, в соответствии с земельным законодательством обладает правом на предоставление ей земельного участка из земель, находящихся в государственной или муниципальной собственности, в собственность бесплатно. В 2014 году гражданка Л.В. Рагимова подала заявление для реализации этого права и была внесена в список граждан, имеющих право на получение земельного участка для осуществления индивидуального жилищного строительства. Между тем земельный участок семье не был предоставлен, несмотря на то, что в соответствии с пунктом 13 статьи 32.1 Земельного кодекса Республики Татарстан он должен быть передан в порядке очередности не позднее одного года с даты включения в списки, за исключением случая, предусмотренного пунктом 15 этой же статьи, согласно которому при троекратном отказе от выбора земельного участка либо троекратной неявке на процедуру выбора земельного участка гражданин исключается из списка.

По утверждению заявительницы, Земельный кодекс Республики Татарстан предусматривает в качестве единственно возможного отступления от предоставления гражданам земельных участков в порядке очередности не позднее одного года с даты включения в списки их троекратный отказ от выбора земельного участка либо троекратную неявку на процедуру выбора земельного участка.

В рамках реализации полномочий, основанных на оспариваемом законодательном положении, Кабинет Министров Республики Татарстан постановлением от 31 декабря 2013 года № 1132 утвердил Порядок использования критериев определения очередности проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан, нацеленный на осуществление единого подхода к определению очередности проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан при формировании региональной программы капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах.

Оспариваемый Закон Республики Татарстан образует с вышеприведенным подзаконным актом единый нормативный комплекс, из содержания которого следует, что очередность проведения капитального ремонта при формировании региональной программы капитального ремонта определяется исходя из критериев, установленных частью 3 статьи 11 данного Закона Республики Татарстан.

Соответственно, то обстоятельство, что порядок использования критериев определения очередности проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан дается не в самом законе, а в подзаконном нормативном правовом акте, притом что сами эти критерии закреплены непосредственно в Законе Республики Татарстан, не свидетельствует о неконституционности соответствующего правового регулирования, поскольку подзаконный акт в этом случае лишь конкретизирует

уже установленное на законодательном уровне правовое регулирование.

Таким образом, часть 4 статьи 11 Закона Республики Татарстан принята в пределах полномочий, предоставленных законодательному органу субъекта Российский Федерации в области жилищного законодательства, основана на приведенных выше положениях федерального законодательства, не может рассматриваться как нарушающая конституционные права и свободы человека и гражданина, в том числе и заявительницы, и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о ее соответствии Конституции Республики Татарстан. В связи с этим согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» жалоба гражданки Л.Е. Колоярцевой не является допустимой. Внесение же целесообразных, с точки зрения заявительницы, изменений в оспариваемое правовое регулирование не входит в компетенцию Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена статьей 109 Конституции Республики Татарстан и статьей 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктами 1 и 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**определил:**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Л.Е. Колоярцевой на нарушение ее конституционных прав и свобод частью 4 статьи 11 Закона Республики Татарстан от 25 июня 2013 года № 52-ЗРТ «Об организации проведения капитального ремонта общего имущества в многоквартирных домах в Республике Татарстан», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Л.Е. Колоярцевой и в Государственный Совет Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 34-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
14 ноябрь
Казан шәһәре

# БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен алдан өйрәнгән судья Р.Г. Сәхиева бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Л.Е. Колоярцева «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Законы) 11 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Законының дәгъвалана торган нормасы әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийларын (алга таба шулай ук — критерийлар) куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә дип күздә тота.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, гражданка Л.Е. Колоярцева 1964 елда төзелгән күпфатирлы йортта яши, анда, аның раславы буенча, капиталь ремонт беркайчан да ясалмаган. Әлеге күпфатирлы йорт Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1146 номерлы карары белән расланган 2014—2043 елларда гамәлгә ашырылу срогы белән Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортлардагы уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау буенча региональ программага (алга таба шулай ук — капиталь ремонт буенча региональ программа) кертелгән, һәм капиталь ремонт әлеге йортта 2016 елга планлаштырылган булган. Ләкин, мөрәҗәгать итүче күрсәткәнчә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 6 октябрендәге 718 номерлы карары белән аның йорты 2016 елда капиталь ремонт буенча региональ программаны тормышка ашыруның кыска вакытлы планыннан төшереп калдырылган.

Гражданка Л.Е. Колоярцева билгеләгәнчә, Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 3 өлеше буенча күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгы капиталь ремонт буенча региональ программада Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән һәм муниципаль берәмлекләр буенча дифференциацияләнергә мөмкин булган критерийлардан чыгып билгеләнә. Югарыда аталган закон нигезләмәсен үтәү йөзеннән «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 3 өлешендә тиешле критерийлар саналган. Аның фикеренчә, мондый җайга салуны Россия Федерациясе Торак кодексы белән каралган формада критерийлар билгеләү дип санарга ярамый, федераль закон чыгаручы тарафыннан Россия Федерациясе субъекты закон чыгаручысына тапшырылган вәкаләтләр региональ законда, чиратлылыкны билгеләү критерийларын куллану тәртибен кертеп, чиратлылыкны билгеләүнең бөтен механизмын җайга салу бурычын аңлата. Шул ук вакытта әлеге Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 4 өлеше буенча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына күрсәтелгән чиратлылыкны билгеләү критерийларын куллану тәртибен билгеләү хокукы бирелгән. Шуның нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийларын куллану тәртибе расланган.

Мөрәҗәгать итүче санаганча, чиратлылыкны билгеләү критерийларын куллану тәртибен законга буйсынулы дәрәҗәдә беркетү Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 3 өлешенең аларны бары тик Россия Федерациясе субъекты законы белән генә билгеләүне күздә тота торган күрсәтмәсенә туры килми. Федераль закон чыгаручы тарафыннан каралмаган мондый хокукый җайга салу, аның фикеренчә, хокукый билгесезлек һәм хокук мөнәсәбәтләренең тотрыксызлыгына һәм ахыр чиктә аның конституциячел хокуклары һәм ирекләренең бозылуына китерә.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Л.Е. Колоярцева Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 4 өлешен Татарстан Республикасы Конституциясенең 2, 17 (икенче өлеш), 18 (икенче өлеш), 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (өченче өлеш) һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Конституциясе нигезендә торак законнары Россия Федерациясенең һәм Россия Федерациясе субъектларының уртак карамагында (72 статья, 1 өлешнең «к» пункты); Россия Федерациясе һәм Россия Федерациясе субъект-

ларының уртак карамагындагы мәсьәләләр буенча федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган Россия Федерациясе субъектларының законнары һәм башка норматив хокукый актлары чыгарыла (76 статья, 2 өлеш).

Россия Федерациясе Торак кодексының 5 статьясындагы 6 өлеше, 167 статьясы һәм 168 статьясындагы 1 өлешенең үзара бәйле нигезләмәләре буенча Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары Россия Федерациясе субъекты территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итүгә юнәлдерелгән законнар һәм башка норматив хокукый актлар кабул итә, алар белән шул исәптән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаларны әзерләү һәм раслау тәртибе, шулай ук әлеге программаларга таләпләр билгеләнә. Шул ук вакытта Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 3 өлеше нигезендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгы капиталь ремонт буенча региональ программада Россия Федерациясе субъекты законы белән билгеләнгән һәм муниципаль берәмлекләр буенча дифференциацияләнергә мөмкин булган критерийлардан чыгып билгеләнә.

Татарстан Республикасында аның территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонтны үз вакытында ясауны тәэмин итү «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» Татарстан Республикасы Законы нигезендә гамәлгә ашырыла. Югарыда күрсәтелгән Россия Федерациясе Торак кодексының 168 статьясындагы 3 өлеше нигезләмәләренә таянып, республика закон чыгаручысы әлеге Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 3 өлешендә күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийларын билгеләгән: техник, оештыру, финанс, шул ук вакытта аларны куллану тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә дип күздә тоткан (11 статьяның 4 өлеше).

Дәгъвалана торган закон нигезләмәсенә таянган вәкаләтләрне гамәлгә ашыру кысаларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты 2013 елның 31 декабрендәге 1132 номерлы карары белән күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт буенча региональ программаны формалаштырганда Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләүгә бердәм алымны гамәлгә ашыруга юнәлдерелгән Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийларын куллану тәртибен раслаган.

Дәгъва белдерелә торган Татарстан Республикасы Законы югарыда күрсәтелгән законга буйсынулы акт белән бердәм норматив комплекс тәшкил итә, аның эчтәлегеннән күренгәнчә, капиталь ремонт буенча региональ программаны формалаштырганда капи-

таль ремонт ясауның чиратлылыгы әлеге Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 3 өлеше белән билгеләнгән критерийлардан чыгып билгеләнә.

Димәк, Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясау чиратлылыгын билгеләү критерийларын куллану тәртибенең законның үзендә түгел, ә законга буйсынулы норматив хокукый актта бирелүе, әлеге критерийлар турыдан-туры Татарстан Республикасы Законында беркетелгән булса да, тиешле хокукый җайга салуның конституциячел булмавы турында расламый, чөнки бу очракта законга буйсынулы акт закон чыгару дәрәҗәсендә билгеләнгән хокукый җайга салуны конкретлаштыра гына.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 4 өлеше Россия Федерациясе субъектының закон чыгару органына торак законнары өлкәсендә бирелгән вәкаләтләр чикләрендә кабул ителгән, югарыда китерелгән федераль закон нигезләмәләренә таянган, кеше һәм гражданның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең дә конституциячел хокукларын һәм ирекләрен боза торган буларак карала алмый һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк. Шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты белән үзара бәйләнештә 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты нигезендә гражданка Л.Е. Колоярцева шикаяте карала алмый. Дәгъвалана торган хокукый җайга салуга мөрәҗәгать итүче фикеренчә максатка ярашлы үзгәрешләр кертү исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясы һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясы белән билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 1 һәм 2 пунктларына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**б и л г е л ә д е :**

1. «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 11 статьясындагы 4 өлеше белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Л.Е. Колоярцевага һәм Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 34-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# ОПРЕДЕЛЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

**об отказе в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Л.Е. Колоярцевой на нарушение ее конституционных прав и свобод постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 сентября 2012 года № 770 «О порядке определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению»**

17 декабря
2018 года
город Казань

Конституционный суд Республики Татарстан в составе Председателя Ф.Г. Хуснутдинова, судей Ф.Р. Волковой, Л.В. Кузьминой, Э.М. Мустафиной, Р.А. Сахиевой, А.Р. Шакараева,

заслушав в судебном заседании заключение судьи Л.В. Кузьминой, проводившей на основании статьи 44 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» предварительное изучение жалобы гражданки Л.Е. Колоярцевой,

**установил:**

1. В Конституционный суд Республики Татарстан обратилась гражданка Л.Е. Колоярцева с жалобой на нарушение ее конституционных прав и свобод постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 сентября 2012 года № 770 «О порядке определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению» (далее также — постановление Кабинета Министров Республики Татарстан).

Оспариваемым постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан принято предложение органов местного самоуправления отдельных муниципальных районов Республики Татарстан о сохранении с 1 сентября 2012 года действующего порядка определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению, утвержденного постановлением Правительства Российской Федерации от 23 мая 2006 года № 307 «О порядке предоставления коммунальных услуг гражданам» (далее также — постановление Правительства Российской Федерации № 307), а также установлено, что при расчете размера платы за коммунальную услугу по отоплению в указанных муниципальных районах применяются нормативы потребления коммунальной услуги по отоплению, действовавшие по состоянию на 30 июня 2012 года.

Из жалобы и приложенных к ней копий документов следует, что заявительница проживает в многоквартирном доме в городе Казани, оснащенном в 2012 году общедомовым прибором учета потребления тепловой энергии, до 2012 года расчет стоимости услуги по отоплению осуществлялся по нормативу. Гражданка Л.Е. Колоярцева указывает, что за периоды отопительных сезонов с 2012 по 2015 годы ООО «Управляющая компания “Уютный дом”» были неправомерно начислены излишние суммы по коммунальной услуге «отопление» в связи с указанием неверной общей площади дома. При этом она отмечает, что в судебном решении мирового судьи об отказе в удовлетворении ее иска к ООО «Управляющая компания “Уютный дом”» была ссылка на обжалуемое постановление Кабинета Министров Республики Татарстан как на нормативный

правовой акт, регулирующий в ее конкретном деле отдельные вопросы по услуге за отопление, тем самым допущена возможность его применения для собственников квартир в городе Казани.

Вместе с тем абзацем четвертым пункта 1 постановления Кабинета Министров Республики Татарстан от 20 августа 2015 года № 611 «О внесении изменений в постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 сентября 2012 года № 770 “О порядке определения размеры платы граждан за коммунальную услугу по отоплению”» город Казань был исключен из числа муниципальных образований, на которые распространяется оспариваемое постановление.

Гражданка Л.Е. Колоярцева полагает, что отсутствие города Казани в числе адресатов оспариваемого постановления Кабинета Министров Республики Татарстан ставит жителей Республики Татарстан, проживающих в различных муниципальных образованиях, в неравное положение и допускает возможность нарушения конституционных прав и свобод в зависимости от места жительства на территории одного и того же субъекта Российской Федерации.

Кроме того, заявительница считает, что Кабинет Министров Республики Татарстан в обжалуемом постановлении установил порядок определения размера платы за коммунальную услугу по отоплению только для граждан, не урегулировав данные вопросы для пользователей (арендаторов). Однако отсутствие в оспариваемом постановлении Кабинета Министров Республики Татарстан правил установления порядка учета потребленной тепловой энергии и порядка расчета услуги по отоплению отдельно для собственников жилых помещений и отдельно для пользователей (арендаторов) нарушает ее конституционные права, так как допускает возможность оплаты жителями многоквартирных домов услуги по отоплению за коммерческие или бюджетные организации.

На основании изложенного гражданка Л.Е. Колоярцева просит Конституционный суд Республики Татарстан признать постановление Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 сентября 2012 года № 770 «О порядке определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению» не соответствующим статьям 28 (части первая и вторая), 29 (часть первая), 49 и 51 Конституции Республики Татарстан.

2. В соответствии с Жилищным кодексом Российской Федерации отношения по поводу предоставления коммунальных услуг и внесения платы за них составляют предмет регулирования жилищного законодательства (пункты 10 и 11 части 1 статьи 4); к жилищным отношениям, связанным с предоставлением коммунальных услуг и внесением платы за них, применяется соответствующее законодательство с учетом требований, установленных данным Кодексом (статья 8). К полномочиям органов государственной власти субъектов Российской Федерации в области жилищных отношений относится, в частности, утверждение размера платы за коммунальные услуги, рассчитываемого исходя из объема потребляемых коммунальных услуг, определяемого по показаниям приборов учета, а при их отсутствии исходя из нормативов потребления коммунальных услуг в порядке, установленном Правительством

Российской Федерации; правила предоставления, приостановки и ограничения предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домах устанавливаются Правительством Российской Федерации (часть 1 статьи 157 Жилищного кодекса Российской Федерации).

Согласно абзацу первому пункта 1 постановления Правительства Российской Федерации от 27 августа 2012 года № 857 «Об особенностях применения в 2012—2014 годах Правил предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов» (далее также — постановление Правительства Российской Федерации № 857) в первоначальной редакции было установлено, что Правила предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов, утвержденные постановлением Правительства Российской Федерации от 6 мая 2011 года № 354 «О предоставлении коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов» (далее также — постановление Правительства Российской Федерации № 354), в части определения размера платы за предоставленную коммунальную услугу по отоплению применяются в 2012—2014 годах с учетом одной из предусмотренных данным постановлением особенностей.

Так, в соответствии с подпунктом «б» пункта 1 постановления Правительства Российской Федерации № 857, действовавшим на момент принятия оспариваемого акта, органам государственной власти субъектов Российской Федерации было разрешено до 15 сентября 2012 года принять решение о применении при расчете размера платы за коммунальную услугу по отоплению порядка расчета размера платы за коммунальную услугу по отоплению в соответствии с Правилами предоставления коммунальных услуг гражданам, утвержденными постановлением Правительства Российской Федерации № 307, используя при этом нормативы потребления тепловой энергии на отопление, действовавшие по состоянию на 30 июня 2012 года.

Таким образом, Кабинет Министров Республики Татарстан, основываясь на вышеуказанном постановлении Правительства Российской Федерации № 857, принял обжалуемое постановление, сохранив с 1 сентября 2012 года для отдельных муниципальных образований, по их предложению, в том числе и для города Казани до 1 октября 2015 года, действовавший в то время порядок определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению равномерно в течение года, утвержденный постановлением Правительства Российской Федерации № 307, и предусмотрев, что при расчете размера платы за коммунальную услугу по отоплению в муниципальных районах (городе) применяются нормативы потребления коммунальной услуги по отоплению, действовавшие по состоянию на 30 июня 2012 года.

Что касается вопроса внесения изменений в оспариваемое постановление Кабинета Министров Республики Татарстан, уточняющих муниципальные образования, в которых сохранялся прежний порядок определения размера платы граждан за коммунальную

услугу по отоплению, Конституционный суд Республики Татарстан отмечает, что согласно пункту 2 постановления Правительства Российской Федерации № 857 органы государственной власти субъектов Российской Федерации, принявшие решение с учетом одной из предусмотренных данным постановлением особенностей определения размера платы за предоставленную коммунальную услугу по отоплению, могут в любой момент принять решение о применении порядка расчета размера платы за коммунальную услугу по отоплению, предусмотренного Правилами предоставления коммунальных услуг собственникам и пользователям помещений в многоквартирных домах и жилых домов, утвержденными постановлением Правительства Российской Федерации от 6 мая 2011 года № 354.

На основании приведенной выше нормы Кабинет Министров Республики Татарстан принимал свои решения о внесении изменений в обжалуемое постановление, тем самым определяя, в каких муниципальных образованиях Республики Татарстан применялись прежний порядок расчета размера платы за коммунальную услугу по отоплению и нормативы потребления коммунальной услуги по отоплению, действовавшие по состоянию на 30 июня 2012 года.

Постановление Правительства Российской Федерации № 354 вступило в силу в полном объеме с 1 июля 2016 года, установив единый для всех порядок расчета размера платы за коммунальную услугу по отоплению, а также исключив ранее предусмотренную возможность для органов государственной власти субъектов Российской Федерации устанавливать дифференцированный подход к определению размера платы за данную коммунальную услугу. При этом действующее ранее постановление Правительства Российской Федерации № 307 было признано утратившим силу. Во исполнение вышеприведенных федеральных нормативных правовых актов обжалуемое постановление было признано утратившим силу постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 20 ноября 2018 года № 1019.

Таким образом, оспариваемое заявительницей правовое регулирование было принято в рамках предоставленных ранее федеральным законодательством субъектам Российской Федерации полномочий, с учетом возможности его применения в отношении отдельных муниципальных образований (по их предложению), расположенных на территории Республики Татарстан, не устанавливало собственного правового регулирования, а потому само по себе не могло считаться нарушающим конституционные права граждан, в том числе заявительницы в указанном в жалобе аспекте, и, следовательно, не содержит неопределенности в вопросе о его соответствии Конституции Республики Татарстан, в связи с чем согласно пункту 2 части первой статьи 46 во взаимосвязи с пунктом 1 части второй статьи 39 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» ее жалоба не является допустимой.

Относительно доводов гражданки Л.Е. Колоярцевой об отсутствии в оспариваемом постановлении Кабинета Министров Республики Татарстан правил установления порядка учета потребленной

тепловой энергии и порядка расчета услуги по отоплению отдельно для собственников жилых помещений и отдельно для пользователей (арендаторов) необходимо отметить, что такое регулирование обусловлено распределением компетенции, предусмотренной Жилищным кодексом Российской Федерации, который регламентирование указанных вопросов не относит к полномочиям органов государственной власти субъектов Российской Федерации.

Определение же правильности произведенных гражданке Л.Е. Колоярцевой расчетов за отопление, равно как проверка и оценка судебного решения по конкретному делу заявительницы с точки зрения его законности и обоснованности, предполагает исследование фактических обстоятельств дела, что не относится к компетенции Конституционного суда Республики Татарстан, как она определена в статье 109 Конституции Республики Татарстан и статье 3 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан».

На основании изложенного, руководствуясь статьей 3, пунктом 1 части второй статьи 39, пунктом 2 части первой статьи 46, частью пятой статьи 66, частями первой и второй статьи 67, статьями 69, 72, 73, 100 и 101 Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан», Конституционный суд Республики Татарстан

**о п р е д е л и л :**

1. Отказать в принятии к рассмотрению жалобы гражданки Л.Е. Колоярцевой на нарушение ее конституционных прав и свобод постановлением Кабинета Министров Республики Татарстан от 14 сентября 2012 года № 770 «О порядке определения размера платы граждан за коммунальную услугу по отоплению», поскольку жалоба в соответствии с установленными требованиями Закона Республики Татарстан «О Конституционном суде Республики Татарстан» не является допустимой, а разрешение поставленного заявительницей вопроса Конституционному суду Республики Татарстан неподведомственно.

2. Определение Конституционного суда Республики Татарстан по данной жалобе окончательно и обжалованию не подлежит.

3. Копию настоящего Определения направить гражданке Л.Е. Колоярцевой и в Кабинет Министров Республики Татарстан.

4. Настоящее Определение подлежит опубликованию в «Вестнике Конституционного суда Республики Татарстан».

№ 35-О

Конституционный суд
Республики Татарстан

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КОНСТИТУЦИЯ СУДЫның

**«Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 14 сентябрендәге 770 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен карауга алудан баш тарту турында**

2018 ел
17 декабрь
Казан шәһәре

## БИЛГЕЛӘМӘСЕ

Татарстан Республикасы Конституция суды, Рәисе Ф.Г. Хөснетдинов, судьялары Ф.Р. Волкова, Л.В. Кузьмина, Э.М. Мостафина, Р.Г. Сәхиева, А.Р. Шакараев составында,

суд утырышында «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 44 статьясы нигезендә гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен алдан өйрәнгән судья Л.В. Кузьмина бәяләмәсен тыңлаганнан соң

**ачыклады:**

1. Татарстан Республикасы Конституция судына гражданка Л.Е. Колоярцева «Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 14 сентябрендәге 770 номерлы карары (алга таба шулай ук — Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары) белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата шикаять белән мөрәҗәгать итте.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карары белән Татарстан Республикасының аерым муниципаль районнары җирле үзидарә органнарының 2012 елның 1 сентябреннән «Гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 23 маендагы 307 номерлы карары (алга таба шулай ук — Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 307 номерлы карары) белән расланган ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләүнең гамәлдәге тәртибен саклау турындагы тәкъдиме кабул ителгән, шулай ук күрсәтелгән муниципаль районнарда ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплап чыгарганда 2012 елның 30 июне хәленә карата гамәлдә булган ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәтүдән файдалану нормативлары кулланыла дип билгеләнгән.

Шикаятьтән һәм аңа кушымта итеп бирелгән документлар күчермәләреннән аңлашылганча, мөрәҗәгать итүче Казан шәһәрендә 2012 елда җылылык энергиясен куллануны исәпкә алуның гомумйорт приборы белән җиһазландырылган күпфатирлы йортта яши, 2012 елга кадәр ягып җылыту буенча хезмәт күрсәткән өчен түләү бәясен хисаплау норматив буенча башкарылган. Гражданка Л.Е. Колоярцева 2012 елдан 2015 елга кадәрге ягулык сезоннары чорларында «“Уютный дом” идарәче

компаниясе» ҖЧҖ тарафыннан, йортның гомуми мәйданы дөрес күрсәтелмәү сәбәпле, «ягып җылыту» коммуналь хезмәте буенча артык түләү бәяләре законсыз хисапланган булган дип күрсәтә. Шул ук вакытта ул билгеләгәнчә, аның «“Уютный дом” идарәче компаниясе» ҖЧҖ карата дәгъвасын канәгатьләндерүдән баш тарту турында җәмәгать судьясының суд карарында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелә торган карарына аның конкрет эшендә ягып җылыту хезмәте буенча аерым мәсьәләләрне җайга сала торган норматив хокукый акт буларак сылтама ясалган, шул рәвешле аны Казан шәһәрендәге фатир милекчеләре өчен куллану мөмкинлеге расланган.

Шул ук вакытта «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләү тәртибе турында” 2012 елның 14 сентябрендәге 770 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 елның 20 августындагы 611 номерлы карарының 1 пунктындагы дүртенче абзацы белән Казан шәһәре дәгъва белдерелә торган карарга карый торган муниципаль берәмлекләр арасыннан төшереп калдырылган.

Гражданка Л.Е. Колоярцева фикеренчә, Казан шәһәренең Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъва белдерелә торган карары адресатлары арасында булмавы төрле муниципаль берәмлекләрдә яшәүче Татарстан Республикасы халкын тигезсез хәлгә куя һәм Россия Федерациясенең бер үк субъекты территориясендә яшәү урынына бәйле рәвештә конституциячел хокуклар һәм ирекләрнең бозылу мөмкинлегенә ирек бирә.

Моннан тыш, мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәгъва белдерелә торган карарда ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү тәртибен, бу мәсьәләләрне файдаланучылар (арендалаучылар) өчен җайга салмыйча, бары тик гражданнар өчен генә билгеләгән дип саный. Ләкин Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карарында кулланылган җылылык энергиясен исәпкә алу тәртибен һәм ягып җылыту буенча хезмәтне хисаплау тәртибен билгеләү кагыйдәләренең аерым торак урыннар милекчеләре өчен һәм аерым файдаланучылар (арендалаучылар) өчен булмавы аның конституциячел хокукларын боза, чөнки күпфатирлы йортларда яшәүчеләр тарафыннан ягып җылыту буенча хезмәткә коммерцияле яки бюджет оешмалары өчен түләү мөмкинлегенә юл куя.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданка Л.Е. Колоярцева Татарстан Республикасы Конституция судыннан «Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның 14 сентябрендәге 770 номерлы карарын Татарстан Республикасы Конституциясенең 28 (беренче һәм икенче өлешләр), 29 (беренче өлеш), 49 һәм 51 статьяларына туры килми дип тануны сорый.

2. Россия Федерациясе Торак кодексы нигезендә коммуналь

хезмәтләр күрсәтү һәм алар өчен түләү кертү буенча мөнәсәбәтләр торак законнарының җайга салу предметын тәшкил итә (4 статьяның 1 өлешендәге 10 һәм 11 пунктлары); коммуналь хезмәтләр күрсәтү һәм алар өчен түләү кертү белән бәйле торак мөнәсәбәтләренә карата, әлеге Кодекста билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, тиешле законнар кулланыла (8 статья). Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарының торак мөнәсәбәтләре өлкәсендәге вәкаләтләренә, аерым алганда, коммуналь хезмәтләр өчен түләү күләмен исәпкә алу приборларының күрсәткечләре буенча, ә алар булмаганда Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларыннан чыгып ачыклана торган кулланылган коммуналь хезмәтләрнең күләменнән чыгып раслау керә; күпфатирлы йортлардагы һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләрне күрсәтү, күрсәтүдән туктатып тору һәм күрсәтүдә чикләү кагыйдәләре Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә (Россия Федерациясе Торак кодексының 157 статьясындагы 1 өлеше).

«2012—2014 елларда Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләрен куллану үзенчәлекләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 27 августындагы 857 номерлы карарының (алга таба шулай ук — Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 857 номерлы карары) 1 пунктындагы беренче абзацының башлангыч редакциясе буенча шул билгеләнгән булган: «Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары (алга таба шулай ук — Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 354 номерлы карары) белән расланган Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләү өлешендә 2012—2014 елларда әлеге карар белән каралган үзенчәлекләрнең берсен исәпкә алып кулланылалар.

Шулай, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 857 номерлы карарының 1 пунктындагы дәгъвалана торган акт кабул ителгән вакытта гамәлдә булган «б» пунктчасы нигезендә Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына 2012 елның 15 сентябренә кадәр ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплаганда Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 307 номерлы карары белән расланган Гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре нигезендә, 2012 елның 30 июне хәленә карата гамәлдә булган ягып җылыту өчен җылылык энергиясеннән файдалану нормативларын кулланып, ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплау тәртибен куллану турында карар кабул итәргә рөхсәт ителгән булган.

Шулай итеп, Татарстан Республикасы Министрлар Каби-

неты, югарыда күрсәтелгән Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 857 номерлы карарына нигезләнеп, 2012 елның 1 сентябреннән аерым муниципаль берәмлекләр өчен, аларның тәкъдиме буенча, шул исәптән 2015 елның 1 октябренә кадәр Казан шәһәре өчен Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 307 номерлы карары белән расланган гражданнарның ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен ел дәвамында тигез итеп түләве күләмен билгеләүнең ул вакытта гамәлдә булган тәртибен саклап һәм муниципаль районнарда (шәһәрдә) ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплап чыгарганда 2012 елның 30 июне хәленә карата гамәлдә булган ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәтүдән файдалану нормативлары кулланыла дип күздә тотып, дәгъвалана торган карарны кабул иткән.

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карарына ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләүнең элеккеге тәртибе сакланган муниципаль берәмлекләрне тәгаенли торган үзгәрешләр кертү мәсьәләсенә килгәндә, Татарстан Республикасы Конституция суды шуны билгеләп үтә: Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 857 номерлы карарының 2 пункты нигезендә Россия Федерациясе субъектларының ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен билгеләүнең әлеге карар белән каралган үзенчәлекләренең берсен исәпкә алып карар кабул иткән дәүләт хакимияте органнары теләсә кайсы вакытта Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган Күпфатирлы йортлар һәм торак йортлардагы урыннар милекчеләренә һәм кулланучыларына коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләре белән каралган ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплау тәртибен куллану турында карар кабул итәргә мөмкин.

Югарыда китерелгән норма нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты дәгъва белдерелә торган карарга үзгәрешләр кертү турындагы карарларын кабул итеп, шуның белән Татарстан Республикасының кайсы муниципаль берәмлекләрендә ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплауның элеккеге тәртибе һәм 2012 елның 30 июне хәленә карата гамәлдә булган ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәтүдән файдалану нормативлары кулланылганын билгеләгән.

Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен түләү күләмен хисаплауның һәркем өчен бердәй тәртибен билгеләп, шулай ук элегрәк каралган Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары өчен әлеге коммуналь хезмәт өчен түләү күләмен билгеләүгә дифференциацияләнгән якын килүне билгеләү мөмкинлеген төшереп калдырып, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 354 номерлы карары тулы күләмдә үз көченә 2016 елның 1 июленнән кергән. Шул ук вакытта элегрәк гамәлдә булган Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 307 номерлы карары үз көчен югалткан дип танылган. Югарыда китерелгән федераль норматив хокукый актларны үтәү йөзеннән дәгъва белдерелә торган карар

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 20 ноябрендәге 1019 номерлы карары белән үз көчен югалткан дип танылган.

Шулай итеп, мөрәҗәгать итүче тарафыннан дәгъва белдерелә торган хокукый җайга салу, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан аерым муниципаль берәмлекләргә карата (аларның тәкъдиме буенча) аны куллану мөмкинлеген исәпкә алып, элек федераль законнар белән Россия Федерациясе субъектларына бирелгән вәкаләтләр кысаларында кабул ителгән, үзенең хокукый җайга салуын билгеләмәгән, шуңа күрә дә үзеннән-үзе гражданнарның, шул исәптән мөрәҗәгать итүченең шикаятьтә күрсәтелгән аспектта конституциячел хокукларын боза торган булырак санала алмаган һәм, димәк, аның Татарстан Республикасы Конституциясенә туры килү-килмәве мәсьәләсендә билгесезлек юк, шуңа бәйле рәвештә «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пункты белән үзара бәйләнештә 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пункты нигезендә аның шикаяте карала алмый.

Гражданка Л.Е. Колоярцеваның Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының дәгъвалана торган карарында кулланылган җылылык энергиясен исәпкә алу тәртибен һәм ягып җылыту буенча хезмәтне хисаплау тәртибен билгеләү кагыйдәләренең аерым торак урыннар милекчеләре өчен һәм аерым файдаланучылар (арендалаучылар) өчен булмавы турындагы дәлилләренә карата шуны билгеләп үтәргә кирәк: мондый җайга салу Россия Федерациясе Торак кодексында каралган компетенцияне бүлүгә бәйле, ул әлеге мәсьәләләрне регламентлауны Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә кертми.

Гражданка Л.Е. Колоярцевага ягып җылыту өчен хисапланган түләүләрнең дөрес булу-булмавын билгеләү исә, мөрәҗәгать итүченең конкрет эше буенча суд карарын законлы һәм нигезле булу-булмавы ягыннан тикшерү һәм бәяләү кебек, эшнең фактлагы хәлләрен тикшерүне күздә тота, бу исә Татарстан Республикасы Конституция судының Татарстан Республикасы Конституциясенең 109 статьясында һәм «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясында билгеләнгән компетенциясенә керми.

Бәян ителгәннәр нигезендә, «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законының 3 статьясына, 39 статьясындагы икенче өлешенең 1 пунктына, 46 статьясындагы беренче өлешенең 2 пунктына, 66 статьясындагы бишенче өлешенә, 67 статьясындагы беренче һәм икенче өлешләренә, 69, 72, 73, 100 һәм 101 статьяларына таянып, Татарстан Республикасы Конституция суды

**билгеләде:**

1. «Ягып җылыту буенча коммуналь хезмәт күрсәткән өчен гражданнар түләве күләмен билгеләү тәртибе турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 елның

14 сентябрендәге 770 номерлы карары белән үзенең конституциячел хокуклары һәм ирекләре бозылуга карата гражданка Л.Е. Колоярцева шикаятен карауга алудан баш тартырга, чөнки шикаять «Татарстан Республикасы Конституция суды турында» Татарстан Республикасы Законы билгеләгән таләпләр нигезендә карала алмый, ә мөрәҗәгать итүче куйган мәсьәләне хәл итү Татарстан Республикасы Конституция суды карамагына керми.

2. Бу шикаять буенча Татарстан Республикасы Конституция суды Билгеләмәсе катгый һәм аңа карата шикаять бирелми.

3. Әлеге Билгеләмәнең күчермәсен гражданка Л.Е. Колоярцевага һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрергә.

4. Әлеге Билгеләмә «Татарстан Республикасы Конституция суды хәбәрләре»ндә басылып чыгарга тиеш.

№ 35-О

Татарстан Республикасы
Конституция суды

# РАЗДЕЛ II.

# ДЕЯТЕЛЬНОСТЬ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

## РЕШЕНИЕ КОНСТИТУЦИОННОГО СУДА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

### О поощрении благодарственными письмами Конституционного суда Республики Татарстан

г. Казань 25 октября 2018 года

В соответствии с Положением о Благодарственном письме Конституционного суда Республики Татарстан, утвержденным решением Конституционного суда Республики Татарстан от 1 марта 2012 года № 1-Р, Конституционный суд Республики Татарстан

**р е ш и л :**

За большой вклад в воспитание студенческой молодежи, подготовку кадров для судебной системы поощрить Благодарственным письмом Конституционного суда Республики Татарстан:

— Мифтахова Рената Ленаровича, заместителя заведующего кафедрой государственно-правовых дисциплин Казанского филиала Федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Российский государственный университет правосудия»;

— Самович Юлию Владимировну, профессора кафедры государственно-правовых дисциплин Казанского филиала Федерального государственного бюджетного образовательного учреждения высшего образования «Российский государственный университет правосудия».

№ 7-Р

Конституционный суд
Республики Татарстан

ДЛЯ ЗАМЕТОК

ДЛЯ ЗАМЕТОК